ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

от 31.01.2017 г. Казань № 16

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 2015 елның 05 февралендәге 29 номерлы боерыгы белән расланган Товарларга (эшләргә, хезмәтләргә) дәүләт тарафыннан җайга салынырга тиешле бәяләрне (тарифларны, өстәмәләрне, арттыруларны) куллануның дөреслегенә һәм аларның зурлыкларының нигезле булуына төбәк дәүләт контрольлеген (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру буенча дәүләт вазыйфасын үтәү буенча Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты административ регламентына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты (алга таба – Дәүләт комитеты) норматив-хокукый актын законнарга туры китерү максатларында б о е р ы к б и р ә м:

1. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 2015 елның 05 февралендәге 29 номерлы боерыгы белән расланган Товарларга (эшләргә, хезмәтләргә) дәүләт тарафыннан җайга салынырга тиешле бәяләрне (тарифларны, өстәмәләрне, арттыруларны) куллануның дөреслегенә һәм аларның зурлыкларының нигезле булуына төбәк дәүләт контрольлеген (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру буенча дәүләт вазыйфасын үтәү буенча Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты административ регламентына (Дәүләт комитетының 2016 елның 09 мартындагы 50 номерлы боерыгы нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.2 пунктка түбәндәге эчтәлекле кызыл юлны өстәргә:

"Бердәм тикшерүләр реестры" федераль дәүләт мәгълүмат системасына (алга таба – бердәм тикшерүләр реестры) мәгълүмат кертү Дәүләт комитетының вәкаләтле вазыйфаи заты тарафыннан гамәлгә ашырыла.";

1.3 пунктны түбәндәге редакциясендә бәян итәргә:

"1.3. Дәүләт комитеты тарафыннан дәүләт вазыйфасы түбәндәгеләр нигезендә

гамәлгә ашырыла:

Россия Федерациясе Гражданлык кодексы (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 05.12.1994, № 32, 3301 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясенең Административ хокук бозулар турында кодексы (алга таба – РФ КоАП) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 07.01.2002, № 1 (1 өл.), 1 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Су кодексы (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 05.06.2006, № 23, 2381 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Урман кодексы (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 11.12.2006, № 50, 5278 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

"Табигый монополияләр турында" 1995 елның 17 августындагы 147-ФЗ номерлы Федераль закон (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 21.08.1995, № 34, 3426 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

"Калдыклар турында" 1998 елның 24 июнендәге 89-ФЗ номерлы Федераль закон (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, № 26, 29.06.1998, 3009 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

"Россия Федерациясендә газ белән тәэмин итү турында" 1999 елның 31 мартындагы 69-ФЗ номерлы Федераль закон (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 05.04.1999, № 14, 1667 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

"Электр энергетикасы турында" 2003 елның 26 мартындагы 35-ФЗ номерлы Федераль закон (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 31.03.2003, № 13, 1177 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

"Коммуналь комплекс оешмалары тарифларын җайга салу нигезләре турында" 2004 елның 30 декабрендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 03.01.2005, № 1 (1 өлеше), 36 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

"Дәүләт контрольлеген (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольлекне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм шәхси эшмәкәрләрнең хокукларын яклау турында" 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы Федераль закон (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 29.12.2008, № 52 (1 өл.), 6249 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

"Дару чаралары әйләнеше турында" 2010 елның 12 апрелендәге 61-ФЗ номерлы Федераль закон (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 19.04.2010, № 16, 1815 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

"Җылы белән тәэмин итү турында" 2010 елның 27 июлендәге 190-ФЗ номерлы Федераль закон (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 02.08.2010, № 31, 4159 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

"Транспорт чараларын техник карау турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында" 2011 елның 1 июлендәге 170-ФЗ номерлы Федераль закон (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 04.07.2011, № 27, 3881 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

"Юридик затларның аерым төрләре тарафыннан товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алулар турында" 2011 елның 18 июлендәге 223-ФЗ номерлы Федераль закон (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 25.07.2011, № 30 (1 өл.), 4571 ст.,

кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

"Су белән тәэмин итү һәм су бүлү турында" 2011 елның 7 декабрендәге 416-ФЗ номерлы Федераль закон (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 12.12.2011, № 50, 7358 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

"Россия Федерациясендә гражданнарга социаль хезмәт күрсәтү нигезләре турында" 2013 елның 28 декабрендәге 442-ФЗ номерлы Федераль закон (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 30.12.2013, № 52 (1 өлеше), 7007 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Президентының "Бәяләрне (тарифларны) дәүләт тарафыннан җайга салуны тәртипкә китерү чаралары турында" 1995 елның 28 февралендәге 221 номерлы Указы (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 06.03.1995, № 10, 859 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең "Россия Федерациясендә үзйөрешле машиналарның һәм башка техника төрләренең техник торышына дәүләт күзәтчелеге турында" 1993 елның 13 декабрендәге 1291 номерлы карары (Россия Федерациясе Президенты һәм Хөкүмәте актлары җыелмасы, 20.12.1993, № 51, 4943 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең "Бәяләрне (тарифларны) дәүләт тарафыннан җайга салуны тәртипкә китерү чаралары турында" 1995 елның 7 мартындагы 239 карары (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 13.03.1995, № 1, 997 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең "Газга һәм аны җитештерү чималына бәяләрне дәүләт тарафыннан җайга салуны тәртипкә китерү чаралары турында" 1995 елның 15 апрелендәге 332 номерлы карары (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 24.04.1995, № 17, 1539 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең "Россия Федерациясендә торак фондын дәүләт исәбенә алу турында" 1997 елның 13 октябрендәге 1301 номерлы карары (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, № 42, 20.10.1997, 4787 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең "Россия Федерациясе территориясендә газга бәяләрне, аны транспортлау хезмәтләренә тарифларны һәм газкулланучы җайланманы газ бүлү челтәрләренә технологик тоташтырганга түләүне дәүләт тарафыннан җайга салу турында" 2000 елның 29 декабрендәге 1021 номерлы карары (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 08.01.2001, № 2, 175 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең "Электр энергиясен тапшыру хезмәтләреннән дискриминацияләнмәгән рәвештә файдалану һәм мондый хезмәтләрне күрсәтү кагыйдәләрен, Электр энергетикасында оператив-диспетчерлык идарәлеге хезмәтләреннән дискриминацияләнмәгән рәвештә файдалану һәм мондый хезмәтләрне күрсәтү кагыйдәләрен, Күмәртәләп сату базарының сәүдә системасы администраторы хезмәтләреннән дискриминацияләнмәгән рәвештә файдалану һәм мондый хезмәтләрне күрсәтү кагыйдәләрен һәм Электр энергиясен кулланучыларның энергияне кабул итү җайланмаларын, электр энергиясен җитештерү буенча объектларны, шулай ук

челтәр оешмаларыныкы һәм башка затларныкы булган электр хуҗалыгы объектларын электр челтәрләренә технологик тоташтыру кагыйдәләрен раслау турында" 2004 елның 27 декабрендәге 861 номерлы карары (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 27.12.2004, № 52 (2 өлеше), 5525 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең "Транспорт терминалларында, портларда, аэропортларда табигый монополия субъектларының хезмәтләренә һәм эчке су юллары инфраструктурасыннан файдалану хезмәтләренә бәяләрне (тарифларны, җыемнарны) дәүләт тарафыннан җайга салу турында" 2008 елның 23 апрелендәге 293 номерлы карары (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 28.04.2008, № 17, 1887 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең "Коммуналь комплекс оешмалары эшчәнлеге өлкәсендә бәя хасил итү нигезләре һәм тарифларны, өстәмәләрне һәм чик дәрәҗә индексларын җайга салу тәртибе турында" 2008 елның 14 июлендәге 520 номерлы карары (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 21.07.2008, № 29 (2 өл.), 3518 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең "Россия Федерациясе субъектларының тарифларны дәүләт тарафыннан җайга салу өлкәсендәге башкарма хакимият органнарының табигый монополия субъектлары эшчәнлеген дәүләт тарафыннан җайга салуны һәм контрольдә тотуны гамәлгә ашыруда катнашуы хакында" 2008 елның 10 декабрендәге 950 номерлы карары (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 15.12.2008, № 50, 5971 ст.);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең "Гомер өчен зарури һәм әһәмиятле дару препаратлары исемлегенә кертелгән дару препаратларына бәяләрне дәүләт тарафыннан җайга салу турында" 2010 елның 29 октябрендәге 865 номерлы карары (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 08.11.2010, № 45, 5851 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең "Транспорт чараларына техник карау үткәрү турында" 2011 елның 5 декабрендәге 1008 номерлы карары (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 12.12.2011, № 50, 7397 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең "Электр энергетикасында җайга салынулы бәяләр (тарифлар) өлкәсендә бәя хасил итү турында" 2011 елның 29 декабрендәге 1178 номерлы карары (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 23.01.2012, № 4, 504 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең "Электр энергиясен ваклап сату базарларының вазыйфалавы, электр энергиясен куллану режимын тулысынча һәм (яки) өлешчә чикләү турында" 2012 елның 4 маендагы 442 номерлы карары (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 04.06.2012, № 23, 3008 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең "Җылы белән тәэмин итү өлкәсендә бәя хасил итү турында" 2012 елның 22 октябрендәге 1075 номерлы карары (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 29.10.2012, № 44, 6022 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең "Су белән тәэмин итү һәм су бүлү өлкәсендә тарифларны дәүләт тарафыннан җайга салу турында" 2013 елның 13 маендагы 406 номерлы карары (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 20.05.2013, № 20, 2500 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең "Дәүләт тарафыннан җайга салынулы бәяләр (тарифлар) өлкәсендә дәүләт контрольлеге (күзәтчелеге), шулай ук Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларын көчен югалткан дип тану турында" 2013 елның 27 июнендәге 543 номерлы карары (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 08.07.2013, № 27, 3602 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең "Бердәм тикшерүләр реестрын формалаштыру һәм алып бару кагыйдәләре турында" 2015 елның 28 апрелендәге 415 номерлы карары (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 11.05.2015, № 19, 2825 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең "Каты коммуналь калдыклары белән эш итү өлкәсендә бәя хасил итү турында" 2016 елның 30 маендагы 484 номерлы карары (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 06.06.2016, № 23, 3331 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгының "Дәүләт контрольлегенен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольлекне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм шәхси эшмәкәрләрнең хокукларын яклау турында" Федераль закон нигезләмәләрен тормышка ашыру турында" 2009 елның 30 апрелендәге 141 номерлы боерыгы (Российская газета, № 85, 14.05.2009, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

"Татарстан Республикасында урманнардан файдалану турында" 2008 елның 22 маендагы 22-ТРЗ Татарстан Республикасы Законы (Республика Татарстан, № 110, 30.05.2008, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

"Тоткарланган транспорт чараларын махсуслаштырылган тукталыш урынына күчерү, аларны саклау, кайтарып бирү, аларны күчерү һәм саклау чыгымнарын түләү тәртибе турында" 2012 елның 17 маендагы 24-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (Республика Татарстан, № 100, 26.05.2012, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

"Татарстан Республикасында гражданнарга социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында" 2014 елның 18 декабрендәге 126-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (Республика Татарстан, № 186, 20.12.2014);

"Россия Федерациясендә автомобиль транспорты һәм шәһәр җир өсте электр транспорты белән пассажирларны һәм багажны даими ташуларны оештыру турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында" 2015 елның 26 декабрендәге 107-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (Республика Татарстан, № 188, 29.12.2015, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының "Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты мәсьәләләре" 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимияте органнары норматив актлары

җыентыгы, 04.08.2010, № 29, 1195 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының "Татарстан Республикасында транспорт чараларын техник карауны үткәрү өчен чик дәрәҗәдә түләү күләмнәрен һәм техник карау талоны дубликатын рәсмиләштерүгә чик дәрәҗәдә чыгымнар күләмен билгеләү турында" 2011 елның 27 декабрендәге 1079 номерлы карары (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимияте органнары норматив актлары җыентыгы, 31.01.2012, № 8, 0296 ст.);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының "Татарстан Республикасында өйдә социаль хезмәт күрсәтү рәвешендә социаль хезмәтләр җиткерүчеләр тарафыннан социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибен раслау турында" 2014 елның 29 декабрендәге 1053 номерлы карары (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимияте органнары норматив актлары җыентыгы, 30.01.2015, № 7-8, 0201 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып).";

1.6 пунктында:

2 нче кызыл юлдагы "юридик затларны, шәхси эшмәкәрләрне тикшерүләрне оештыру һәм үткәрү аша" сүзләрен "юридик затларны, шәхси эшмәкәрләрне тикшерүләрне оештыру һәм үткәрү, зарури таләпләрне бозуларны профилактикалау буенча чаралар оештыру һәм үткәрү аша" сүзләренә алмаштырырга;

3 нче кызыл юлдагы "юридик затның, шәхси эшмәкәрнең аталган затлар тарафыннан файдаланылучы" "тикшерү буенча документларын карау буенча" сүзләрен "юридик затның, шәхси эшмәкәрнең аталган затлар тарафыннан файдаланылучы" "карау һәм тикшерү буенча документларын һәм аларның эшчәнлекләре турында башка төрле мәгълүматны карау буенча" сүзләренә алмаштырырга;

беренче бүлекне түбәндәге эчтәлекле 1.6.1 пункты белән тулыландырырга:

"1.6.1. Юридик затлар һәм шәхси эшмәкәрләр тарафыннан зарури таләпләр бозылуларны кисәтү, зарури таләпләрне бозуларга китерә торган сәбәпләрне, факторларны һәм шартларны юкка чыгару максатларында Дәүләт комитеты ел саен үзе тарафыннан расланучы бозуларны профилактикалау программасы нигезендә зарури таләпләрне бозуларны профилактикалау буенча чараларны гамәлгә ашыра.";

1.7 пунктында:

1.7 пунктны түбәндәге редакциясендә бәян итәргә:

"1.7.1. Дәүләт комитетының тикшерү үткәрүгә вәкаләтле вазыйфаи затлары түбәндәгеләргә хокуклы:

– дәлилле язмача гарызнамәләр нигезендә юридик затлардан, шәхси эшмәкәрләрдән тикшерүне үткәрү барышында кирәкле булган мәгълүматны һәм документларны соратырга һәм алырга;

– түләүсез нигездә, шул исәптән электрон рәвештә Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән исемлеккә кертелгән документларны һәм (яки) мәгълүматны шушы документлар һәм (яки) мәгълүмат белән эш итүче бүтән дәүләт органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан яисә дәүләт органнарының яки җирле үзидарә органнарының ведомство буйсынуындагы оешмалардан

ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән чорларда һәм тәртиптә соратырга һәм алырга;

– Россия Федерациясе законнарында каралган тәртиптә ачыкланган бозу фактлары буенча Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән чараларны күрергә.";

1.7.2 пунктчасында:

тугызынчы кызыл юлда "(бу кызыл юл таләбе 2016 елның 1 июленнән гамәлдә)" сүзләрен төшереп калдырырга;

унбишенче кызыл юлны төшереп калдырырга;

уналтынчы кызыл юлда "(бу кызыл юл таләбе 2016 елның 1 июленнән гамәлдә)" сүзләрен төшереп калдырырга;

түбәндәге эчтәлекле кызыл юлны өстәргә:

"– 2016 елның 1 гыйнварыннан башлап 2018 елның 31 декабренә кадәрге чорда планлы тикшерү үткәргәндә юридик затның җитәкчесенә, башка вазыйфаи затына яки вәкаләтле вәкиленә, шәхси эшмәкәргә, аның вәкаләтле вәкиленә 294-ФЗ номерлы Федераль законның 26.1 статьясы нигезләмәләре эчтәлеген аңлатырга.";

1.7.3 пунктчаны түбәндәге редакциясендә бәян итәргә:

"1.7.3. Дәүләт комитетының тикшерү үткәрүгә вәкаләтле вазыйфаи затлары түбәндәгеләргә хокуклы түгел:

– әгәр дә мондый таләпләр Дәүләт комитеты вәкаләтләренә карамаса, аның исеменнән гамәл кылучы вазыйфаи затлар буларак зарури таләпләр үтәлешен тикшерергә;

– аны үткәргәндә юридик затның җитәкчесе, бүтән вазыйфаи заты яки вәкаләтле вәкиле, шәхси эшмәкәр, аның вәкаләтле вәкиле булмый торган очракта планлы яки планнан тыш урынга чыгып тикшерүне гамәлгә ашырырга;

– СССР һәм РСФСР башкарма хакимиятя органнарының норматив-хокукый актларында билгеләнгән һәм Россия Федерациясе законнарына туры килми торган таләпләрнең үтәлешен тикшерергә (бу кызыл юл таләбе 2017 елның 30 июненнән башлап гамәлдә);

– СССР һәм РСФСР башкарма хакимитя органнарының норматив-хокукый актларында билгеләнгән таләпләрнең үтәлешен, шулай ук Россия Федерациясе законнарында үтәлеше каралмаган норматив документларның таләпләре үтәлешен тикшерергә (бу кызыл юл таләбе 2017 елның 1 июленнән гамәлдә);

– Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгарылмаган хокукый актларда билгеләнгән зарури таләпләрнең үтәлешен тикшерергә;

– әгәр дә алар тикшерү объектлары булмаса яки тикшерү предметына карамасалар, документларны һәм мәгълүмат тапшыруны таләп итәргә, шулай ук мондый документларның чын нөсхәләрен алырга;

– тикшерү үткәрү нәтиҗәсендә алынган һәм дәүләт, коммерция, хезмәт серен, закон белән саклана торган башка төрле серне тәшкил итүче мәгълүматны таратырга, Россия Федерациясе законнарында каралган очраклардан тыш;

–тикшерү үткәрүнең билгеләнгән чорларын арттырырга;

– юридик затларга, шәхси эшмәкәрләргә алар хисабына контрольлек буенча

чаралар үткәрү турында күрсәтмәләр яки тәкъдимнамәләр бирүне гамәлгә ашырырга;

– юридик заттан, шәхси эшмәкәрдән, башка дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары яисә дәүләт органнарына яки җирле үзидарә органнарына буйсынучы оешмалар карамагында булган рөхсәт итү документларын да кертеп, Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән исемлеккә кертелүче документларны һәм (яки) мәгълүматны тапшыруларын таләп итәргә;

– юридик заттан, шәхси эшмәкәрдән тикшерүне үткәрә башлаган датага кадәр документлар, мәгълүмат тапшыруны таләп итәргә. Дәүләт комитеты тикшерү үткәрү турында боерык кабул итегәч кирәкле документларны һәм (яки) мәгълүматны ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында соратырга хокуклы.";

1.8 пунктындагы 1.8.1 пунктчасының җиденче, сигезенче кызыл юлларында "(бу кызыл юл таләбе 2016 елның 1 июленнән гамәлдә)" сүзләрен төшереп калдырырга;

1.9 пунктында:

1 пунктчадагы "шушы Регламентка 1 кушымтага туры китерелгән рәвештә" сүзләрен төшереп калдырырга;

3 пунктчада "тикшерүләрне исәпкә алу журналында" сүзләреннән соң "ул юридик затта, шәхси эшмәкәрдә булган очракта" сүзләрен өстәргә;

түбәндәге эчтәлекле пунктчаны өстәргә:

"4) 294-ФЗ номерлы Федераль законның 13.3 статьясы һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2015 елның 28 апрелендәге 415 номерлы карары нигезендә бердәм тикшерүләр реестрына кертелгән тиешле мәгълүмат.";

түбәндәге эчтәлекле кызыл юлны өстәргә:

"Әгәр дә дәүләт вазыйфасын үтәү өчен ДӘүләт комитетына гражданнардан, шул исәптән шәхси эшмәкәрләрдән, юридик затлардан мөрәҗәгатьләр һәм гаризалар, дәүләт хакимияте органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, массакүләм мәгълүмат чараларыннан мәгълүмат килү нигез булып торса, дәүләт вазыйфасын үтәү нәтиҗәләре буенча мөрәҗәгать итүчегә "Россия Федерациясе гражданнарының мөрәҗәгатьләрен карап тикшерү тәртибе турында" 2006 елның 2 маендагы 59-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән тәртиптә җавап җибәрелә.".";

2.1 пунктының 2.1.6 пунктчасын түбәндәге редакциясендә бәян итәргә:

"2.1.6. Дәүләт комитетының рәсми сайтында түбәндәге мәгълүмат урнаштырыла:

– әлеге Регламент;

– Дәүләт комитеты рәисе боерыгы белән расланган еллык Юридик затларга һәм шәхси эшмәкәрләргә планлы тикшерүләр үткәрү планы (алга таба – еллык План);

– норматив-хокукый актларның яки аларның үтәлешен бәяләү төбәк дәүләт контрольлегенең (күзәтчелегенең) предметы булып торган зарури таләпләрне үз өченә алучы өлешләренең исемлеге, шулай ук тиешле норматив-хокукый актларның текстлары;

– төбәк дәүләт контрольлеген (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру тәҗрибәсен даими (елга бер мәртәбәдән ешрак түгел) гомумиләштерү буенча мәгълүматлар, шул исәптән иң еш очрый торган зарури таләпләрне бозу очракларын, юридик затлар, шәхси эшмәкәрләр тарафыннан мондый бозуларны булдырмау максатларында күрелергә тиешле чараларга карата киңәшләрне күрсәтеп.";

2.3 пунктының 2.3.1 пунктчасының дүртенче кызыл юлында "Тикшерүне үткәргәндә" сүзләрен "Урынга чыгып планлы тикшерүләрне үткәргәндә" сүзләренә алмаштырырга, "(бу кызыл юл таләбе 2016 елның 1 июленнән гамәлдә)" сүзләрен төшереп калдырырга;

2.4 пунктында:

2.4.3 пунктчасын түбәндәге редакциясендә бәян итәргә:

"2.4.3. Юридик затка һәм шәхси эшмәкәргә планнан тыш тикшерү үткәрү өчен түбәндәгеләр нигез булып тора:

– юридик зат, шәхси эшмәкәр тарафыннан Дәүләт комитеты тарафыннан элек бирелгән ачыкланган зарури таләпләрне бозуны юкка чыгару турында күрсәтмәне үтәү чоры бетү;

– Дәүләт комитеты рәисенең Россия Федерациясе Президенты, Россия Федерациясе Хөкүмәте йөкләмәләренә туры китереп һәм прокурорның прокуратура органнарына килгән материаллар һәм мөрәҗәгатьләр буенча законнарның үтәлешенә күзәтчелек итү кысаларында планнан тыш тикшерү үткәрү турындагы таләбе нигезендә чыгарылган боерыгы.";

түбәндәге эчтәлекле 2.4.4.1 пунктчаны өстәргә:

"2.4.4.1. Әгәр дә юридик зат, шәхси эшмәкәр тарафыннан ачыкланган зарури таләпләрне бозуны юкка чыгару турында күрсәтмәнең үтәлү чорының тәмамлануы планнан тыш тикшерүне үткәрү өчен нигез булып торса, мондый тикшерүнең предметы булып бары тик дәүләт контрольлеге (күзәтчелеге) органы тарафыннан бирелгән күрсәтмәнең үтәлеше генә тора ала.";

2.4.5 пунктчаны түбәндәге редакциясендә бәян итәргә:

"2.4.5. Дәүләт комитетына мөрәҗәгать итүче затны ачыкларга мөмкинлек бирми торган мөрәҗәгатьләр һәм гаризалар, шулай ук 2.4.4 пунктында күрсәтелгән фактлар турында мәгълүматлары булмаган мөрәҗәгатьләр һәм гаризалар планнан тыш тикшерүне үткәрү өчен нигез булып хезмәт итә алмыйлар. Мөрәҗәгать итүче тарафыннан электрон документлар рәвешендә җибәрелгән мөрәҗәгатьләр һәм гаризалар аларның мөрәҗәгать итүче тарафыннан мөрәҗәгать итүченең бердәм идентификация һәм аутентификация системасында зарури авторлаштырылган булуын күздә тотучы мәгълүмати-коммуникация технологияләре чараларыннан файдаланып җибәрелгән булу шарты белән генә планнан тыш тикшерү үткәрү өчен нигез булып хезмәт итә алалар.";

түбәндәге эчтәлекле 2.4.6 пунктчасын өстәргә:

"2.4.6. Дәүләт комитетының рәисе, рәисенең урынбасары карары буенча,

әгәр дә ул башланганчыга кадәр аны оештыру нигезе булган мөрәҗәгатьнең яки гаризаның аноним булуы ачыкланса, яисә мөрәҗәгатьтә яки гаризада белә торып төгәл булмаган белешмәләрнең булуы билгеләнсә, планнан тыш тикшерү туктатыла.";

3 бүлекнең 1 таблицасында:

2 пунктның 4 графасын түбәндәге редакциясендә бәян итәргә: "Электр энергетикасы турында" 2003 елның 26 мартындагы 35-ФЗ номерлы Федераль законның 21 статьясының 4 өлеше, 24 статьясының 3 өлеше; Россия Федерациясе Хөкүмәтенең "Электр энергетикасында җайга салынулы бәяләр (тарифлар) өлкәсендә бәя хасил итү турында" 2011 елның 29 декабрендәге 1178 номерлы карары";

12 пунктның 3 графасында "Төбәк операторлары тарафыннан, каты коммуналь калдыклары белән эш итү буенча операторлар тарафыннан мәгълүмат ачу стандартлары таләпләренең үтәлеше" сүзләрен төшереп калдырырга;

12 пунктның 4 графасында:

"2014 елның 30 декабрендәге Федераль закон" сүзләрен "2004 елның 30 декабрендәге Федераль закон" сүзләренә алмаштырырга;

"Россия Федерациясе Хөкүмәтенең "Каты коммуналь калдыклары белән эш итү өлкәсендә бәя хасил итү турында" 2016 елның 30 маендагы 484 номерлы карары" сүзләрен өстәргә;

4 бүлекнең 2 таблицасындагы 2.13 пунктның 3 графасында "05.04.2007 № 204 Ростехнадзор боерыгы" сүзләрен төшереп калдырырга;

5 бүлекнең сигезенче кызыл юлын түбәндәге редакциясендә бәян итәргә:

"Россия Федерациясе законнарында каралган очракларда дәүләт вазыйфасы үтәлешен туктатып тору рөхсәт ителә.";

5.1 пунктында "(боерыкның үрнәк рәвеше шушы Регламентка 7 кушымтада китерелде)" сүзләрен төшереп калдырырга;

5.2 пунктында:

5.2.3 пунктчасының икенче кызыл юлында "шушы Регламентка 7 кушымтага туры китерелгән рәвеш буенча" сүзләрен "Россия Икътисадый үсеш министрлыгының 2009 елның 30 апрелендәге 141 номерлы боерыгы белән расланган рәвеш буенча" сүзләренә алмаштырырга;

5.2.4 пунктчасында:

беренче кызыл юлдагы "яисә башка төрле мөмкин булган ысул белән (факсимиль элемтә, электрон почта ярдәмендә, алу турында тамга белән кулдан)" сүзләрен "һәм (яки) көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган һәм юридик затның, шәхси эшмәкәрнең электрон адресы буенча җибәрелгән электрон документ ярдәмендә, әгәр дә мондый адрес бердәм дәүләт юридик затлар реестрында, бердәм дәүләт шәхси эшмәкәрләр реестрында тиешенчә булса яисә юридик зат, шәхси эшмәкәр тарафыннан Дәүләт комитетына элегрәк тапшырылган булса, яки башка төрле мөмкин ысул белән" сүзләренә алмаштырырга;

икенче кызыл юлдагы "Дәүләт комитетының тиешле боерыгы чыгарыла" сүзләрен "тиешле акт төзелә" сүзләренә алмаштырырга;

дүртенче кызыл юлда "өч эш көне дәвамында" сүзләрен "өч эш көнендә" сүзләренә алмаштырырга;

5.2.5 пунктчасында:

өченче кызыл юлда "Россия Федерациясе Хөкүмәте билгели торган тәртиптә" сүзләрен төшереп калдырырга;

алтынчы кызыл юлда "(бу кызыл юл таләбе 2016 елның 1 июленнән гамәлдә)" сүзләрен төшереп калдырырга;

5.2.6 пунктчасының унынчы кызыл юлын түбәндәге редакциясендә бәян итәргә:

"Әгәр дә элегрәк тапшырылган документларның дөреслеген раслап тапшырылучы аңлатмалаларны һәм документларны карап тикшергәннән соң, яисә аңлатмалар аңлатмалар булмаганда Дәүләт комитеты зарури таләпләрне бозу билгеләрен билгеләсә, Дәүләт комитетының вазыйфаи затлары урынга чыгып тикшерү үткәрергә хокуклы, аны үткәргәндә юридик заттан, шәхси эшмәкәрдән документар тикшерүне үткәргәндә алар тарафыннан тапшырылган документларны һәм (яки) мәгълүматны таләп итү рөхсәт ителми. Мондый очракта документар тикшерү нәтиҗәсе "Юридик затка, шәхси эшмәкәргә урынга чыгып планлы тикшерү үткәрү" административ процедурасын башкаруны башлау нигезенә туры киләчәк".";

5.2.7 пунктчасының беренче кызыл юлында "шушы Регламентка 1 кушымтага туры китерелгән рәвеш буенча" сүзләрен "Россия Икътисадый үсеш министрлыгының 2009 елның 30 апрелендәге 141 номерлы боерыгы белән расланган рәвеш буенча" сүзләренә алмаштырырга;

5.2.11 пунктчасында "(бу кызыл юл таләбе 2016 елның 1 июленнән гамәлдә)" сүзләрен төшереп калдырырга;

5.3 пунктында:

түбәндәге эчтәлекле 5.3.3.1 пунктчасын өстәргә:

"5.3.3.1. Әгәр дә шәхси эшмәкәрнең, аның вәкаләтле вәкиленең, юридик зат җитәкчесенең яки бүтән вазыйфаи затының булмый торуы сәбәпле, яисә юридик затның, шәхси эшмәкәрнең фактта эшчәнлеге гамәлгә ашырылмау сәбәпле, яисә шәхси эшмәкәрнең, аның вәкаләтле вәкиленең, юридик зат җитәкчесенең яки бүтән вазыйфаи затының тикшерү үткәрүнең мөмкин булмавына китереп чыгарган башка гамәлләре (гамәл кылмавы) аркасында урынга чыгып планлы тикшерүне үткәрү мөмкин булмаса, Дәүләт комитеның вазыйфаи заты, аны үткәрүнең мөмкин булмау сәбәпләрен күрсәтеп, тиешле тикшерүне үткәрүнең мөмкин булмавы хакында акт төзи. Бу очракта Дәүләт комитеты тиешле тикшерүне үткәрүнең мөмкин булмавы хакында актны төзегән көннән башлап өч ай дәвамында мондый юридик затка, шәхси эшмәкәргә карата, планлы тикшерүне еллык планлы тикшерүләр планына кертмичә һәм юридик затка, шәхси эшмәкәргә алдан хәбәр итмичә, урынга чыгып планнан тыш тикшерү үткәрү хакында карар кабул итәргә хокуклы.";

5.3.4 пунктчасының беренче кызыл юлында "шушы Регламентка 1 кушымтага туры китерелгән рәвеш буенча" сүзләрен "Россия Икътисадый үсеш министрлыгының 2009 елның 30 апрелендәге 141 номерлы боерыгы белән расланган рәвеш буенча" сүзләренә алмаштырырга;

5.3.6 пунктчасында:

беренче кызыл юлда "юридик затны, шәхси эшмәкәрне тикшерүләрне исәпкә алу журналында" сүзләреннән соң "(ул булган очракта)" сүзләрен өстәргә;

өченче кызыл юлда "юридик затны, шәхси эшмәкәрне тикшерүләрне исәпкә алу журналында" сүзләреннән соң "(ул булган очракта)" сүзләрен өстәргә;

5.3.8 пунктчасында "(бу кызыл юл таләбе 2016 елның 1 июленнән гамәлдә)" сүзләрен төшереп калдырырга;

5.4 пунктында:

5.4.5 пунктчасында:

икене кызыл юлда "Россия Федерациясе Хөкүмәте билгели торган тәртиптә" сүзләрен төшереп калдырырга;

бишенче кызыл юлда "(бу кызыл юл таләбе 2016 елның 1 июленнән гамәлдә)" сүзләрен төшереп калдырырга;

5.4.7 пунктчасының беренче кызыл юлында "шушы Регламентка 1 кушымтага туры китерелгән рәвеш буенча" сүзләрен "Россия Икътисадый үсеш министрлыгының 2009 елның 30 апрелендәге 141 номерлы боерыгы белән расланган рәвеш буенча" сүзләренә алмаштырырга;

5.4.10 пунктчасында "(бу кызыл юлдагы таләп 2016 елның 1 июленнән гамәлдә)" сүзләрен төшереп калдырырга;

5.5 пунктында:

5.5.4 пунктчасының беренче кызыл юлында:

"2.4.3, 2.4.4 пунктларының 2 пунктчаларында" сүзләрен "2.4.4 пунктының 2 пунктчасында" сүзләренә алмаштырырга;

"теләсә нинди мөмкин булган ысул белән" сүзләреннән соң "шул исәптән көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган һәм юридик затның, шәхси эшмәкәрнең электрон адресы буенча җибәрелгән электрон документ ярдәмендә, әгәр дә мондый адрес бердәм дәүләт юридик затлар реестрында, бердәм дәүләт шәхси эшмәкәрләр реестрында тиешенчә булса яисә юридик зат, шәхси эшмәкәр тарафыннан Дәүләт комитетына элегрәк тапшырылган булса" сүзләрен өстәргә;

түбәндәге эчтәлекле 5.5.5.1 пунктчасын өстәргә:

"5.5.5.1. Әгәр дә шәхси эшмәкәрнең, аның вәкаләтле вәкиленең, юридик зат җитәкчесенең яки бүтән вазыйфаи затының булмый торуы сәбәпле, яисә юридик затның, шәхси эшмәкәрнең фактта эшчәнлеге гамәлгә ашырылмау сәбәпле, яисә шәхси эшмәкәрнең, аның вәкаләтле вәкиленең, юридик зат җитәкчесенең яки бүтән вазыйфаи затының тикшерү үткәрүнең мөмкин булмавына китереп чыгарган башка гамәлләре (гамәл кылмавы) аркасында урынга чыгып планнан тыш тикшерүне үткәрү мөмкин булмаса, Дәүләт комитеның вазыйфаи заты, аны үткәрүнең мөмкин булмау сәбәпләрен күрсәтеп, тиешле тикшерүне үткәрүнең мөмкин булмавы хакында акт төзи. Бу очракта Дәүләт комитеты тиешле тикшерүне үткәрүнең мөмкин булмавы хакында актны төзегән көннән башлап өч ай дәвамында мондый юридик затка, шәхси эшмәкәргә карата, юридик затка, шәхси эшмәкәргә алдан хәбәр итмичә, урынга чыгып планнан тыш тикшерү үткәрү хакында карар кабул итәргә хокуклы.";

5.5.8 пунктчасында:

беренче кызыл юлда "юридик затны, шәхси эшмәкәрне тикшерүләрне исәпкә алу журналында" сүзләреннән соң "(ул булган очракта)" сүзләрен өстәргә;

өченче кызыл юлда "юридик затны, шәхси эшмәкәрне тикшерүләрне исәпкә алу журналында" сүзләреннән соң "(ул булган очракта)" сүзләрен өстәргә;

5.5.10 пунктчасында "(бу кызыл юлдагы таләп 2016 елның 1 июленнән гамәлдә)" сүзләрен төшереп калдырырга;

Товарларга (эшләргә, хезмәтләргә) дәүләт тарафыннан җайга салынырга тиешле бәяләрне (тарифларны, өстәмәләрне, арттыруларны) куллануның дөреслегенә һәм аларның зурлыкларының нигезле булуына төбәк дәүләт контрольлеген (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру буенча дәүләт вазыйфасын үтәү буенча Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты административ регламентына 1 кушымтаны төшереп калдырырга;

Товарларга (эшләргә, хезмәтләргә) дәүләт тарафыннан җайга салынырга тиешле бәяләрне (тарифларны, өстәмәләрне, арттыруларны) куллануның дөреслегенә һәм аларның зурлыкларының нигезле булуына төбәк дәүләт контрольлеген (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру буенча дәүләт вазыйфасын үтәү буенча Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты административ регламентына 6 кушымтаны шушы боерыкка карата кушымтага туры китерелгән редакциясендә бәян итәргә;

Товарларга (эшләргә, хезмәтләргә) дәүләт тарафыннан җайга салынырга тиешле бәяләрне (тарифларны, өстәмәләрне, арттыруларны) куллануның дөреслегенә һәм аларның зурлыкларының нигезле булуына төбәк дәүләт контрольлеген (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру буенча дәүләт вазыйфасын үтәү буенча Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты административ регламентына 7 кушымтаны төшереп калдырырга.

2. Бу карар аны рәсми бастырып чыгарган көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

3. Әлеге боерык үтәлешен контрольдә тоту буенча үземне җаваплы итеп билгелим.

Рәис М.Р.Зарипов

Татарстан Республикасы

Тарифлар буенча дәүләт комитетының
_________________ №______________
боерыгына кушымта
Товарларга (эшләргә, хезмәтләргә) дәүләт тарафыннан җайга салынырга тиешле бәяләрне (тарифларны, өстәмәләрне, арттыруларны) куллануның дөреслегенә һәм аларның зурлыкларының нигезле булуына төбәк дәүләт контрольлеген (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру буенча дәүләт вазыйфасын
үтәү буенча Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты административ регламентына
6 кушымта

Дәүләт вазыйфасын үтәүнең
БЛОК-СХЕМАСЫ

Еллык тикшерүләр планын формалаштыру, аны прокуратура органы белән килештерү

Планнан тыш тикшерүне үткәрү өчен әлеге Регламентның 2.4.3, 2.4.4 пунктларында күрсәтелгән нигезләрнең башлануы

Планлы тикшерү

Планнан тыш тикшерү

Тикшерү үткәрү турында рәис (рәис урынбасары) боерыгын әзерләү


Юридик затка, шәхси эшмәкәргә планлы тикшерүне үткәрү хакында һәм зарурлык булганда планнан тыш тикшерү үткәреләчәге хакында хәбәр итү

Документар тикшерү

Урынга чыгып тикшерү

Юридик зат, шәхси эшмәкәр адресына кирәкле документларны тапшыру турында хат җибәрү

Дәүләт комитеты вазыйфаи затлары гамәлләренә карата таләпләрне үтәп, урынга чыгып тикшерү үткәрү


Тапшырылган документларны өйрәнү
Урынга чыгып тикшерү үткәрү турында карар кабул итү
Зурари таләпләрне бозу фактының булмавын билгеләү
Зарури таләпләрне бозу фактын билгеләү
Ике нөсхәдә тикшерү акты төзү
Административ хокук бозу турында эш кузгату
Ачыкланган бозуларны бетерү турында күрсәтмә төзү һәм бирү
Тикшерү акты нөсхәсен кушымталарының күчермәләре белән юридик затка, шәхси эшмәкәргә тапшыру яки җибәрү
РФ КоАП нигезендә административ эш башкару
Зарури таләпләрне бозуларны бетерүне тикшереп тору
Тикшерүләрне исәпкә алу журналында (ул булган очракта) үткәрелгән урынга чыгып тикшерү турында язу теркәү"